**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать буенча совет турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать буенча советның эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать буенча совет турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы ПУ-40 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать буенча совет (алга таба – Совет) турындагы нигезләмәдә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«мәдәният өлкәсендә федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеген координацияләү, шулай ук республиканың мәдәният өлкәсендәге дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру барышында мәдәниятне үстерүгә кызыксынган иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмаларны, шул исәптән дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмаларны берләштерүче кластерлар нигезендә системалы караш булдыруны тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр эшләү;

мәдәният, шул исәптән милли мәдәният өлкәсендәге җәмгыять өчен әһәмияткә ия булган проектларны, аларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр эшләү өчен карап тикшерү;

мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә проблемалы мәсьәләләрне ачыклау, фаразлау һәм аларны хәл итү буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр эшләү.»;

3.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Совет эшчәнлеге юнәлешләре буенча мәсьәләләрне карап тикшерү һәм хәл итү өчен эш төркемнәре оештырырга.»;

4.8–4.10 пунктларны үз көчен югалткан дип санарга;

б) Совет составында:

Совет составыннан К.Р. Нәбиуллинаны чыгарырга;

Совет составына Фазлыева Ләйлә Ринат кызын – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарын кертергә;

Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Ш. Әхмәдиеваның – «Казан дәүләт мәдәният институты ректоры (килешү буенча)»;

И.Г. Зәйниевнең – «Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург, «Әкият» татар дәүләт курчак театры сәнгать җитәкчесе (килешү буенча)»;

А.В. Сладковскийның – «Россия Федерациясенең Халык артисты, Татарстан Республикасының Халык артисты, Татарстан Республикасы Дәүләт академия симфония оркестрының сәнгать җитәкчесе – баш дирижеры (килешү буенча)»;

Л.Н. Шарованың – «Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 03 сентябрь
№ ПУ-619